МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.09.2013 № 529

г.Казань

“Татарстан Республикасында күп балалы гаиләгә таныклык рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында” 04.09.2012 ел, №697 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында күп балалы гаиләгә таныклык рәсмиләштерү һәм бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

“Татарстан Республикасында күп балалы гаиләгә таныклык рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында” 04.09.2012 ел, №697 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында күп балалы гаиләгә таныклык рәсмиләштерү һәм бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2,4 пунктларны, 5 пунктның җиденче абзацын төшереп калдырырга;

5 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

“Идарә (бүлек) ведомствоара запрослар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүченең гаиләсе составы турында вәкаләтле оешмалардан мәгълүматлар ала.

Мөрәҗәгать итүчеләр, аларның законлы вәкилләре яки ышанычлылары, үзләренең теләгенә карап, Идарәгә (бүлек) бу пунктның унөченче абзацында күрсәтелгән мәгълүматлардан торучы документлар тапшыруга хокуклы.”;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9. Таныклыкның гамәлдә булу срогы гаиләдә 18 яшькә кадәрге ким дигәндә өч бала булган чорга билгеләнә.

Таныклыкта гамәлдә булу срогы тәмамлану датасы булып күп балалы гаиләдә өч баланың иң зурысына 18 яшь тулу датасы күрсәтелә.”;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10.Таныклыкның гамәлдә булу чорында мөрәҗәгать итүче гаиләсендә бала туганда (уллыкка (кызлыкка) бала алганда) таныклыкның гамәлдә булу срогы озайтыла.

Мөрәҗәгать итүче таныклыкның гамәлдә булу срогын озайту өчен яшәү урыны буенча Идарәгә (бүлек) мөрәҗәгать итеп, бу Тәртипнең 5 пунктындагы өченче, дүртенче, алтынчы абзацларда күздә тотылган документларны тапшыра.”;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“11. Таныклыкның гамәлдә булу срогы гаилә күп балалы гаилә статусын югалткан очракта туктатыла.”

**Министр вазыйфаларын башкаручы** **А.Р.Хәсәнов**